КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 7 август г.Казань № 954

«Педагогларның һөнәри осталыгын һәм квалификациясен бәяләү үзәге» дәүләт автоном учреждениесе исемен үзгәртү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогларның һөнәри осталыгын һәм квалификациясен бәяләү үзәге» дәүләт автоном учреждениесен оештыру турында» 2020 ел, 18 август, 701 нче карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Педагогларның һөнәри осталыгын һәм квалификациясен бәяләү үзәге» дәүләт автоном учреждениесе исемен «Мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри осталыгын бәяләү үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә (алга таба - Үзәк) үзгәртү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогларның һөнәри осталыгын һәм квалификациясен бәяләү үзәге» дәүләт автоном учреждениесен оештыру турында» 2020 ел, 18 август, 701 нче карарына, 2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри компетенцияләрен диагностикалауны мәгълүмати-аналитик тәэмин итү Үзәк эшчәнлегенең төп максаты булып тора;».

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына 60 көн эчендә Үзәк Уставына үзгәрешләр кертергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин